СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2023 с. Сарманово № 200

Сарман муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 444-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы а пунктчасы, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Сарман муниципаль районы Советының 2013 елның 18 декабрендәге 132 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 82 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктына түбәндәге сүзләр өстәргә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 5.1 пункт өстәргә:

«5.1) Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектының дәүләт учреждениеләре (Россия Федерациясе субъекты составына керүче муниципаль берәмлекләрнең муниципаль учреждениеләре) тарафыннан дару чаралары, махсус дәвалау азыгы продуктлары, медицина эшләнмәләре, чыгым материаллары, дезинфекцияләү өчен чаралар, шулай ук тиешле товарларны саклау һәм китерү буенча хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру, Россия Федерациясенең тиешле субъектының дәүләт унитар предприятиесендә яисә акцияләренең йөз проценты Россия Федерациясенең тиешле субъектына караган акционерлык җәмгыятендә медицина эшләнмәләрен ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү буенча эшләр;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район

Советы Рәисе Ф. М. Хөснуллин